| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 ноябрь № 872

г. Казань

2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында

Россия Федерациясе субъектларында конкурентлыкны үстерү стандарты таләпләрен тормышка ашыру, шулай ук Татарстан Республикасының товарлар һәм хезмәтләр базарларында конкурентлыкны үстерү шартларын булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2015 – 2016 елларга Татарстан Республикасында конкурентлыкны үстерү буенча чаралар планын («юл картасын») (алга таба – Юл картасы) расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына Юл картасын тормышка ашыруны тәэмин итәргә һәм ел саен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына аның чараларын үтәү барышы турында хисаплар кертергә:

беренче ярты еллык өчен – хисап елының 1 сентябренә кадәр;

ел өчен – хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан алынган мәгълүмат анализы нигезендә ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Юл картасын тормышка ашыру барышы турында хисап кертергә:

беренче ярты еллык өчен – хисап елының 1 октябренә кадәр;

ел өчен – хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр.

4. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2012 – 2015 елларга Татарстан Республикасының конкурентлы базарларын үстерү программасын раслау турында» 2012 ел, 7 март, 198 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел,

30 сентябрь, 701 нче карарының 1 нче пунктындагы егерме икенче – егерме өченче абзацлары.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Премьер-министр
Республики Татарстан И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\872.docx